**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 23 12 март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 ноябрендэге 92 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 18 августындагы 115 нче номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 14 нче номерлы, 2018 елның 24 апрелендэге 96 нчы номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 118 нче номерлы,, 2018 елның 18 декабрендәге 125 нче номерлы, 2019 елның 8 июлендэге 143-10 номерлы, 2019 елнын 12 ноябрендэге 156-18 номерлы карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Уразай авыл жирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 ноябрендэге 92 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 18 августындагы 115 нче номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 14 нче номерлы, 2018 елның 24 апрелендэге 96 нчы номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 118 нче номерлы,, 2018 елның 18 декабрендәге 125 нче номерлы, 2019 елның 8 июлендэге 143-10 номерлы, 2019 елнын 12 ноябрендэге 156-18 номерлы карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина